Раслыйм:
“Күгәрчен урта гомуми
белем бирү мәктәбе”муниципаль
бюджет белем бирү учреждениясе
директор________М.Г.Мингарипов

Приказ № 15 от 31.08.2020 ел.

# “Күгәрчен урта гомуми белем бирү мәктәбе”муниципаль бюджет белем бирү учреждениясенең мәктәпкәчә төркеменең 2020-2021 нче уку елына эш планы

2020

**Планның эчтәлеге**

1. Кереш өлеш -3
2. Балалар бакчасының 2019 – 2020 нче уку елында эшләгән эшенә анализ – 3-4
3. Балалар бакчасының методик максаты, бурычлары – 5
4. Кадрлар бүленеше – 6
5. Педагогик киңәшмәләр. – 7-8
6. Тематик атналыклар. Коллектив күзәтүләр – 8
7. Күргәзмәлекләр. Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату - 9
8. . Ата – аналар белән жыелышлар – 10
9. Ата – аналар белән индивидуаль эш 10-11
10. Педагогик эшне оештыру буенча айлык циклограммалар. 11-14
11. Административ-хуҗалык эше – 14-15
12. Кугэрчен мәктәбе белән хезмәттәшлек.-15
13. Чыныктыру-сәламәтләндерү буенча эш планы – 15-16
14. Балаларнын кондэлек эшчэнлеклэрен оештыру, тэрбия биру режимы. -17

**Кереш өлеш**

«Каенкай» балалар бакчасы 2009 елнын 1 октябрендэ урта мэктэп бинасына кучерелэ.

Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары – Каримуллина Лилия Габдулхак кызы, югары белемле, педагогик стажы – 19 ел.

Тәрбияче – Фатыйхова Фэния Ильяс кызы, махсус урта белем, педагогик стажы - 36ел.

Тэрбияче, жыр житэкчесе – Мукриева Голусэ Хосэен кызы, югары белем, педагогик стажы – 33 ел

Тэрбияче – Багманова Голусэ Шамил кызы, югары белем, педагогик стажы – 22 ел

Тәрбияче ярдәмчесе – Галимова Гузэл Зиннур кызы кызы –урта белемле, эш стажы – 11 ел.

Повар – Атнагулова Сария Абзал кызы, махсус урта белемле, эш стажы – 38 ел.

Бакчада барысы 4 педагог эшли. Өч югары белемле һәм 1 махсус урта белемле педагоглар тәрбия һәм белем бирә..

1 квалификацион категориягә ия – 3 педагог;
квалификацион категориясез – 1 педагог;

Балалар бакчасында 1 катнаш төркем эшләп килә. Бакчага барысы 17 бала йөри. Тәрбия һәм белем бирү саф татар телендә алып барыла.

**2019-2020 нче уку елының эшчәнлегенә анализ**

«Каенкай» балалар бакчасында 2018-2019 нчы уку елында 1 катнаш төркемдә 20 бала тәрбияләнде.

Уртанчылар һәм II кечкенәләр төркемчегендә: 11

Мәктәпкә әзерлек һәм зурлар төркемчегендә: 9

Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балар тәрбияләү өстендә эшләде. Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтижәле итү өчен яңа идеяләр, белем – тәрбия бирүдә инновацион технологияләр кулану кирәк.

Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игътибар ителде.

Тәрбияче тарафыннан балалар бакчасының укыту – тәрбия планнары, төркемдә белем бирү эшчәнлеге төрләре челтәре төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында төркемнәрдә эшләүче тәрбиячеләр даими рәвештә режим моментларын үтәделәр. Уздырылган эшчәнлекләрнең нәтижәсе буенча һәрбер төркемдә һәр балага индивидуаль диагностика уздырылды. Быелгы уку елында 9 баланы мәктәпкә әзерләп озаттык, аларның һәрберсенә портфолиолар тутырылып бирелде. Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучылары белән ныклы элемтәдә торабыз; алар елга берничә тапкыр балалар бакчасына шөгыльләр карарга киләләр, гомуми киңәшмәләрдә, ата – аналар жыелышларында катнашалар. Балалар белән шулай ук мәктәпкә максатчан экскурсияләр оештырыла.

Уку елы бер-бер артлы уздырылган чаралар белән тыгыз бәйләнеп барылды. Район, авыл күләмендә уткәрелгән чараларда актив катнашып бардык.

Бакчада һәрбер бәйрәм оешкан төстә узды. Ел әйләнәсендә балалар һәм әти – әниләр, әби - бабайлар белән күп кенә чаралар уздырылды.

.

Юл йөру кагыйдәләрен өйрәнү һәм ныгыту максатыннан бакчабызга Кугэрчен участогынын хокук сакчысы килеп балалар белән әңгәмә үткәрде. Балаларның сәләмәтлеген саклау һәм ныгыту максатыннан шәфкать туташы белән ел дәвамында кызыклы әңгәмәләр алып барылды.

Бакчада уздырылган “Алтын Көз”; әниләр көненә «Әни – бөек исем»; яңа елга «Кыш бабайда кунакта»;ватанны саклаучылар көненә «Әтием горурлыгым»; яз бәйрәменә «Әнием

назы»; “Көлке көне”; “Хуш киләсез-кошкайлар”; ;Сау бул –бакча” һәм башка бәйрәм иртәләре балаларның һәм тәрбиячеләрнең зур әзерлеге белән билгеләп үтелде.
Спортка зур игътибар бирелә. Һәр елны участокта тау ясала, чаңгы трассасы салына һәм тәрбиячеләр белән балалар чаңгы шуалар.
Балалар бакчасына йөрүче балалаларның сәламәтлек төркемнәре буенча күренеше түбәндәгечә булды: II-төркем – 24 бала, III- төркем -2 бала, Уртача бер балага авырып калган көн 0,3 көн булды. Әлбәттә балаларның сәламәтлеге өчен дөрес туклану да мөхим роль уйный. Иң элек балалар өчен төзелгән көндәлек менюның эчтәлегенә игътибар ителә.Менюда ризыклар төрләндерелгән, яшелчә, жиләк – жимешләргә дә киң урын бирелә.
Яңа елга балалар бакчасы территориясен эти-әниләр белән берлектә кардан ясалган сыннар белән бизәп матурладык
. Узган уку елында әти -әниләр белән эшләүгә зур игътибар бирелде. Аеруча этиләрнең бакчага ярдәме бик зур. Участокны бизәүдә этиләрнең көче күп керде. Бу уку елында да әти - әниләр белән эшләүгә зур бурычлар куелды. Иң мөхиме әти - әниләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.
Бакчада алга киткән технология һәм методикларга нигезләнеп педагогларның һөнәри камиллеген үстерү, экологик культура, рухи- әхлакый сыйфатлар тәрбияләү юнәлешендә эш алып бару. Шушы максаттан мәгариф министырлыгы тарафыннан кайтарылган укыту - методик комплекты (УМК) ,ноутбук һәм проектр белән эш алып барылды.

**2020- 2021 уку елына балалар бакчасының максаты:**

***Баланың мәктәпкәчә балачагын яхшы сыйфатта яшәве өчен уңайлы шартлар булдыру.***
***Шәхес буларак балада төп культура базасын формалаштыру.***
***Яшь үзенчәлегенә һәм индивидуаль үзенчәлегенә туры китереп төрле яктан психик һәм физик сыйфатын үстерү.***
***Балаларны хәзерге заман җәмгыятендә яшәргә әзерләү.***
***Уку эшчәнлегенә кирәкле шартлар формалаштыру балаларда.***
***Баланың көндәлек эшчәнлегендә куркынычсызлыгын тәэмин итү.***
***Балалар бакчасында балаларга рус һәм татар телләрен өйрәтүне яңа технологияләргә, яңа алымнарга таянып гамәлгә ашыру.***

**бурычлары:**

***1. Балаларның сәламәтлеген саклау технологияләрен кертүне дәвам итүне нәтиҗәле оештыру һәм әти-әниләр белән сәламәт тормыш алып баруны активлаштыру, хәрәкәт активлыгын үстерү өчен шартлар тудыру.***

***2. Балалар бакчасы һәм мәктәп арасындагы дәвамчанлыкны булдыру, федераль дәүләт белем бирү стандартларына таянып тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру.***

***3. Балалар бакчасында укыту - методик комплектын (УМК) кулланып әти-әниләр һәм тәрбиячеләрнең бердәм эшчәнлеген булдыру.Балаларга ике дәүләт телен (рус һәм татар)өйрәтүдә яңа алымнар куллану.***

**Кадрлар бүленеше**
**(2017 – 2018 уку елы)**

| № п/п | Ф.И.О. | Туган елы | Пед. стаж | Вазифасы | Белеме | Квалиф.ка тегор. | Курста | | Аттестация | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | булган | буласы елы | узган | узасы елы |
| 1. | Каримуллина Л.Г. | 1980 | 19 | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары | Югары | 0 | 0 | 2021 | | |
| 2. | Фатыйхова Ф.И. | 1965 | 36 | Тәрбияче | Махсус урта | 1 | 2018 | 2021 | 2020 | 2025 |
| 3. | Мукриева Г.Х. | 1969 | 33 | Тэрбияче Музыка житәкчесе | Югары | 1 | 2018 | 2021 | 2020 | 2025 |
| 4. | Багманова Г.Ш. | 1973 | 22 | Тэрбияче | Югары | 1 | 2018 | 2021 | 2012 | 2022 |

## Педагогикага кагылышлы киңәшмәләр

### Август

**№1 Тема: “Яңа уку елына әзерлек”.**
1.- Балалар бакчасында ФДБС таләпләре;
- УМК белем бирү-тәрбия процессында нәтиҗәле куллануны дәвам итү;
- Балаларны рус теленә өйрәтүгә комплексլы якын килү;
- Яңа уку елына төп бурычлар;
- 2019-2020 нче уку елына план кабул итү;
- Еллык шөгыльләр челтәрен раслау;
- Яңа уку елында аттестация үтүче педагогларның исемлеге белән танышу;
- Төрлеләр;
- Карар кабул итү.

2.Аттестация буенча норматив документлар:
- Аттестация үтүчеләргә киңәшләр.
- Педагогик портфолио әзерләү. Самоанализ, самопрезентация, ачык шөгыльләргә әзерләнү.

### Ноябрь

**№2 Тема: “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга башлангыч һөнәри юнәлеш бирүдә заманча белем бирү технологияләре”.**
- Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга башлангыч һөнәри юнәлеш бирүдә уен технологияләре
-“Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга иртә профориентация бирүдә заманча белем бирү технологияләре" темасына чыгыш»
- Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны иртә профориентацияләүдә уен технологияләрен куллану буенча эш торышының тематик контроль нәтиҗәләре
- Уку елы башында (октябрь) уздырылган мониторинг нәтиҗәләренә анализ.
- Карар кабул итү.

### Гыйнвар

**№3: Тема:“Билингваль белем бирү процессында балалар бакчасында күпкультуралы тәрбия”**
- Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда толерантлык тәрбияләү чарасы буларак мәдәни мохит.
- Балалар бакчасыда “Рус телен өйрәнәбез” эшендә УМК технологияләрен нәтиҗәле куллану”
- Балаларны дәүләт телләренә өйрәтү буенча индивидуаль эштә уеннар һәм ситуатив күнегүләр куллану

### Май

**№4 Тема: “Узган 2019-2020уку елына куелган максатка ирештекме, бурычларыбызны үтәдекме?** (Йомгак ясый торган педагогик киңәшмә. ИКТ кулланып, еллык, аналитик отчетларны презентацияләү. )
1. Узган педагогик киңәшмәнең карар үтәлешен анализлау.
2. 2019-2020 уку елының белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә еллык эш планының үтәлеше, алдагы уку елына перспективалар.

3. Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының мәктәпкә әзерлеген тикшерүгә уздырылган диагностика нәтиҗәләре.
4. “Безнең уңышлар” – тәрбиячеләрнең һәм предмет тәрбиячеләренең эшләнгән эшләре буенча, программа үтәлешләре буенча (мониторинг) отчетлары (тестлар, фото – күргәзмәләр һ.б.)
5. Педагогларның үз белемнәрен күтәрү планнары буенча отчетлары.
6. Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту юнәлешендә эш планы үтәлешенә аналитик, чагыштырулы нәтиҗә.
7. Җәйге белем һәм тәрбия, сәламәтләндерү – профилактик юнәлештә эшчәнлекнең планын кабул итү.
8. Елның җылы вакытына көндәлек режимны, бердәм эшчәнлек челтәрен раслау.

**Тематик атналыклар**

| **Вакыты** | **Эш төре** | **Җаваплы** |
|---|---|---|
| Сентябрь | Сәламәтлек атналыгы | Тәрбияче |
| Сентябрь | Куркынчсызлык атналыгы | Тәрбияче |
| Октябрь | Мәрхәмәтлелек атналыгы | Тәрбияче |
| Ноябрь | Музыка атналыгы | Музыка җитәкчесе |
| Январь | Рус теле атналыгы | Тәрбияче |
| Февраль | Туган тел атналыгы | Тәрбияче |
| Март | “Оста куллар” атналыгы | Тәрбияче |
| Апрель | Г.Тукай атналыгы | Музыка җитәкчесе<br>Тәрбияче |
| Май | Бөек җиңүгә 76 ел уңаеннан хәтер атналыгы | Музыка җитәкчесе<br>Тәрбияче |

**Коллектив күзәтүләр**

| | **Эш төре** | **Җаваплы** | **Вакыты** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | II кечкенәләр төркемендә балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү | Фатихова Ф.И. | Декабрь | |
| 2 | II кечкенәләр төркемендә үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләре тәрбияләү | Багманова Г.Ш. | Ноябрь | |
| 3 | “Изучаем русский язык” эшчәнлегенә тематик тикшеру | Фатихова Ф.И. | Январь | |
| 4 | Уртанчылар төркемендә “танып белү” белем бирү өлкәсе (математика) | Мукриева Г.Х. | Февраль | |
| 5 | Зурлар төркемендә “танып белү” белем бирү өлкәсе (математика) | Мукриева Г.Х. | Март | |

**Күргәзмәлекләр**

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендә оештырылган конкурсларда катнашу | Даими | тәрбияче |
| 2 | “Исәнме алтын көз” – яшелчә, җиләк – җимештән, яфраклардан күргәзмә | Сентябрь- Октябрь | тәрбияче |
| 3 | “Юлларда сак бул.”- юл йөрукагыйдәләре буенча рәсем конкурсы | Сентябрь – Октябрь | тәрбияче |
| 4 | “Әниемэ бүләк итәм чәчәк бәйләме” кулдан ясалган чәчәк букетларына конкурс | Ноябрь | тәрбияче |
| 5 | Яңа ел бәйрәменә кулдан ясалган уенчыкларга конкурс. | Декабрь | тәрбияче |
| 6 | “Серле куллар” - әбиләргә, әтиләргә һәм әниләргә балалар кулы белән эшләнгән бәйрәм бүләге | Февраль, Март | тәрбияче |
| 7 | Г.Тукай әсәрләренә кул эшләренә конкурс | Апрель | тәрбияче |
| 8 | “Минем гаиләм” – рәсем конкурсы | даими | тәрбияче |

**Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату**

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендә үткәрелгән КМО һәм РМО утырышларында, семинарларда катнашу һәм тәҗрибә уртаклашу буенча чыгышлар ясау | Даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары, тәрбиячеләр |
| 2 | Район, республика күләмендә чыга торган газета журналларга үзенең эш тәҗрибәсен язып тарату | Даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары, тәрбиячеләр |
| 3 | Тәрбияченең эш тәҗрибәсе буенча район – республика күләм таратуда матбугат чараларыннан һәм интернеттан нәтиҗәле файдалану. | Даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары, тәрбияче |

**Ата – аналар белән үткәреләчәк жыелышлар**

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | **Тема: “Балалар бакчасының яңа уку елына әзерлеге, 2019 – 2020 уку елына максатлар һәм бурычлар”**<br><br>Көн тәртибе:<br>-Ата-аналар комитеты рәисен, әгъзаларын һәм сәркатибен сайлау.<br>- Яңа уку елына бурычлар һәм бакча эшчәнлеге белән таныштыру.<br>- „Грипкка каршы профилактика“. Күгәрчен авылының фельдшер акушерлык пункты мөдире Мөхәммәтҗанова Диләрә Зиннур кызының чыгышы.<br>- Ата – аналар комитетын сайлау, аталар советы турында сөйләшү<br>- Төрлеләр | Сентябрь | Каримуллина Л.Г.<br><br>. |
| 2 | **Тема: „Сәламәтлек – иң зур байлык”.**<br>- „Каенкай“ балалар бакчасы буенча 2019-2020 уку елына кертелгән яңалыклар, үзгәрешләр, **б**алалар бакчасына түләүләрнең үзгәреше“<br>- „Сәламәт яшәү серләре“<br>- „Мәктәпкә китүче балаларның әти –әниләренә яңалыклар“<br>- „Бакчабызда кышкы рацион“<br>- Төрлеләр. | Январь | Фатыйхова Ф.И. |
| 3 | **Тема: “Гаилә һәм бакчаның берлектә эш нәтиҗәләрен йомгаклау”**<br>- балаларны сәламәтләндерү нәтиҗәләренә анализ;<br>- еллык план бурычларын бурычларын үтәүгә анализ;<br>- җәйге сәламәтләндерү чорына киңәшләр;<br>- әти-әниләр комитеты эшенә анализ. | Май | Каримуллина Л.Г. |

**Ата - аналар белән эш**

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Төркемдәге ата – аналар почмагын яңарту. | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 2 | Ата – аналар белән әңгәмәләр алып бару | Даими | Тәрбиячеләр |
| 3 | “Ачык ишекләр” көне. Ата – аналарның режим моментларында, белем бирү эшчәнлекләрендә, уздырылган чараларда актив катнашуы. | Даими | Тәрбиячеләр. Музыка җитәкчесе |
| 4 | Ата-аналар белән “Изучаем русский язык” темасына анкета уткэру | Ноябрь | Тэрбияче |
| 5 | Башлангыч сыйныф укытучылары белән очрашу | Апрель | Тәрбияче |
| 6 | Ата – аналарның кул эшләреннән күргәзмәләр оештыру, алар ярдәме | Даими | Коллектив |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | белән мастер – класслар күрсәтү | | |
| 7 | “Минем гаилэм” бэйрэме уткэру | Декабрь,апрель | Тэрбиячелэр |

**Педагогик эшне оештыру буенча айлык циклограммалар**

***Сентябрь***

| № | Эш төре | I атна | II атна | III атна | IV атна |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Төркемнәрдә укыту-методик комплектының (УМК) торышын карау | + | + | + | + |
| 2 | Белем бирү өлкәләре эшчәнлеге челтәрен төзү | + | | | |
| 3 | Халыкара матурлык көнен билгеләп үтү | | + | | |
| 4 | Коллектив хезмәткәрләренә инструктаж үткәрү | + | | | |
| 5 | Оператив контроль:Перспектив планнарны, көндәлек документацияне тикшерү.Эчке тәртип кагыйдәләренең, режим моментының үтәлешен тикшерү | + | + | + | + |
| 6 | Педагогларның үз белемен күтәрү, социаль активлыгын арттыру буенча эше | | + | | |
| 7 | Тәркемнәрдә антропометрик тикшерү уздыру, алдагы үлчәү белән чагыштыру, анализ | | | + | |
| 8 | Методик почмакка методик әсбаблар туплау | + | + | + | + |
| 9 | Сәламәтлек һәм куркынычсызлык атналыкларын уздыру | | | + | |
| 10 | Мебельләрдә маркировкаларның дөреслеген тикшерү | + | | | |
| 11 | Ата – аналар белән анкеталар уздыру: “Бакчага сезнең фикерләрегез” | | | | + |
| 12 | “Әти,әни һәм мин”- дип исемләнгән көзге спорт бәйрәмен уздыру | | | | + |
| 13 | Ата – аналар белән әңгәмәләр: “Балаларның иммунитетын көчәйтү”, “Гаиләдә ата абруе”, Диагностика нәтиҗәләре | + | + | + | + |
| 14 | Тәрбиячеләр көнен билгеләп үтү | | | | + |

***Октябрь***

| № | Эш төре | I атна | II атна | III атна | IV атна |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тәрәзәләрне ябыштыру | + | | | |
| 2 | Мәрхәмәтлелек атналыгы уңаеннан “Өлкәннәр көненә” карата балалар иртәләре | + | | | |
| 3 | Төркемнәрдә экология почмакларының торышын карау | | + | | |
| 4 | Балалар белән максатчан экскурсияләр оештыру | + | + | + | + |
| 5 | Балаларны сәламәтләндерү, чыныктыру бенча чаралар үткәрү | + | + | + | + |
| 6 | Адынгы эш тәжрибәләрен өйрәнү, тарату. | + | + | + | + |
| 7 | Ата – аналар белән әңгәмәләр. | + | + | + | + |
| 8 | “Сөмбелә” бәйрәмен уздыру | + | | | |
| 9 | Бакчада электр приборларының төзеклегенә контроль.әңгәмәләр | | | | + |
| 10 | Уен мәйданчыкларын чистарту, чәчәк орлыкларын җыю | + | + | + | + |
| 11 | Бакчаның кышка әзерлеге буенча эшне оештыру | + | + | + | + |
| 12 | Оператив тикшерү; Балалар тормышын, сәламәтлеген | + | + | + | + |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | саклау очен шартлар булуы, саф һавада күзәтүләр. | | | | |

***Ноябрь***

| № | Эш төре | I атна | II атна | III атна | IV атна |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларның шәхси папкалары тупланышына контроль | + | + | + | + |
| | Халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтү | + | | | |
| 2 | Оператив контроль: Педагоголарның яңа укыту методик кулланмаларны максатчан кулланулары, тәрбиячеләрнең балалар уены белән җитәкчелегенә анализ, йокы бүлмәләрендә санитар –гигиеник таләпләргә анализ | + | + | + | + |
| 3 | Алдынгы эш тәҗрибәләрен өйрәнү, тарату | + | + | + | + |
| 4 | Милиционерлар көнен билгеләп үтү | | + | | |
| 5 | Бәйрәм көннәренә дежурлык графигын төзү | + | | | |
| 6 | Хезмәткәрләр белән әңгәмә: “Сәламәт тәндә – сәламәт акыл”. | | | | + |
| 7 | Тематик контроль: “Балаларны рус теленә өйрәтүнең торышы”. | | + | + | |
| 8 | Һәр төркем балалары өчен сәламәтләндерү – чыныктыру буенча комплексlы күнегүләр үткәрү | + | + | + | + |
| 9 | Конституция көнен билгеләп үтү | + | | | |
| 10 | ОРЗ һәм грипкка каршы профилактик чаралар | + | + | + | + |
| 11 | Әтиләр көненә балаларның котлау открыткаларын тапшыру | | + | | |
| 12 | “Эни көненә” әниләр өчен күңел ачу кичәсе | | | | + |
| 13 | Әти-әниләрнең һөнәрләре турында әңгәмә | | + | + | |

***Декабрь***

| № | Эш төре | I атна | II атна | III атна | IV Атна |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Төркемнәрдә сюжетлы уен почмакларының торышы | + | + | | |
| 2 | Балалар рәсемнәренә конкурс “Ур-ра кыш килде” | + | | | |
| 3 | “Яңа ел” бәйрәме уздыру буенча техник куркынычсызлык кагыйдәләре буенча хезмәткәрләр белән киңәшмә уздыру | | + | | |
| 4 | Участокны һәм төркемне бизәү буенча кулдан ясалган уенчыкларга конкурс | | | + | |
| 5 | Саф һавада “Кышкы спартакиада”, уеннары үткәрү.(Әти - әниләр һәм балалар белән берлектә.) | | + | | |
| 6 | Ата – аналар белән берлектә бакча территориясен бизәү максатыннан кардан төрле сыннар ясау | + | + | + | + |
| 7 | Яңа ел бәйрәме программаларын карау, анализлау | + | + | + | + |
| 8 | Оператив контроль: Эчке тәртип кагыйдәләренең сакланышы,көн дәвамында балаларның эшчәнлеген оештыру, бала белән индивидуаль эш, урамда мәйданчыкларның торышы, пожар куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлеше. | + | + | + | + |
| 9 | Ата – аналар белән әңгәмә:“Балаларны чыныктыру”, “Эмоциональ үсеш”, “Балаларның сөйләмен ничек матур, яңгырашлы, сәнгатьле итәргә”. | | | + | + |
| 10 | Ата –аналар белән берлектә Яңа ел бәйрәмен уздыру | | | | + |
| 11 | Яңа ел бәйрәмнәрендә дежурлык графигын төзү | | | | + |
| 12 | Максатчан экскурсияләр | + | + | + | + |
| 13 | УМК материалларының кулланышын һәм торышын карау | | + | | |

***Январь***

| № | **Эш төре** | **I атна** | **II атна** | **III атна** | **IV атна** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Декабрь аенда узган конкурсларга йомгак | + | | | |
| 2 | Алдынгы эш тәҗрибәләрен өйрәнү, тарату | + | + | + | + |
| 3 | Һәр төркемдә хәрәкәт активлыгын үстерүгә спорт бәйрәмнәре | | | + | + |
| 4 | Балаларның шәхси делоларны тулыландыру | | | | + |
| 5 | Оператив контороль: Сәламәтләндерү чараларының утәлеше, прогулкаларны оештыру, авыручанлыкка анализ. | | + | + | + |
| 6 | Электр приборларының төзеклегенә контроль | | | | + |
| 7 | Ата – аналар белән әңгәмәләр: “Туклану физиологиясе”, “Монологик диологиксөйләм өстендә эш”, “Балага җәза кулланмагыз”. | + | + | + | + |
| 8 | Кышкы чорда өлкәннәрнең һәм балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау (бозлавык, боз сөңгеләре) | + | + | + | + |
| 9 | “Кошлар ашханәсе”- Әтиләр кулы белән ясалган җимлекләргә конкурс | + | + | | |
| 10 | Балаларга антропометрик тикшерү уздыру, анализлау | | + | | |

***Февраль***

| № | Эш төре | I атна | II атна | III атна | IV атна |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ватанны саклаучылар көненә карата балалар кулыннан ясалган кул эше күргәзмзсе | | + | | |
| 2 | Алдынгы эш тәҗрибәләрен, өйрәнү, тарату | | + | | |
| 3 | “Әтием – горурлыгым” , әтиләр белән берлектә бәйрәм иртәсе | | | + | |
| 4 | Оператив контроль: Ата-аналар белән эшчәнлек, прогулкаларны оештыру, календарь планнарны карау | + | + | + | + |
| 5 | Максатчан экскурсияләр | + | + | + | + |
| 6 | Авылыбызда булган һөнәр пунктларына экскурсия | + | + | + | + |

***Март***

| № | **Эш төре** | **I атна** | **II атна** | **III атна** | **IV атна** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларның сәламәтлеге буенча эшкә анализ | + | | | |
| 2 | Бөтендөнья җир һәм су көнен билгеләп үтү | | | | + |
| 3 | Мәктәпкә әзерлек төркемендә коллектив күзәтү | | | + | |
| 4 | Алдынгы эш тәҗрибәләрен өйрәнү, тарату | + | + | + | + |
| 5 | “Әнием – алтыным” - әниләр белән берлектә бәйрәм иртәсе | + | | | |
| 6 | Ата - аналар белән әңгәмәләр: “Баланың соравын җавапсыз калдырмагыз”, “Баланың мәктәпкә психологик әзерлеге” | | + | + | |
| 7 | Оператив контроль: Сәламәтләндерү һәм чыныктыру чараларының үтәлеше, рольле-сюжетлы рольләрне оештыру, төркемнәрдә санитар-гигиеник таләпләрнең үтәлеше | + | + | + | + |
| 8 | Халыкара театр көнен билгеләп үтү | | | | + |

***Апрель***

| № | **Эш төре** | **I атна** | **II атна** | **III атна** | **IV атна** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Оператив контроль: Балаларны уенчыклар һәм предметлар ярдәмендә сөйләргә өйрәтү, тәрбиячеләрнең мониторинг | | | | + |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | үткәрү методикасы, участокларның торышы | | | | |
| 2 | Төркемдәге сәламәтлек экранының торышы | + | | | |
| 3 | Алдынгы эш тәҗрибәләрен өйрәнү, тарату | + | + | + | + |
| 4 | Г. Тукай атналыгын уздыру, | | | + | |
| 5 | Г Тукай әсәрләренә рәсем конкурсына йомгак ясау | + | + | + | |
| 6 | Кошлар көненә - балалар иртәсе | + | | | |
| 7 | “Шаяннар көне” – балалар иртәсе | + | | | |
| 8 | Ата аналар белән әңгәмәләр: “Баланың ялы”, Гомуми сөйләм кимчелекләре булган балалар белән эш”, “Балаларны язгы судан саклыйк”. | + | + | + | + |
| 9 | Максатчан экскурсияләр | + | + | + | + |
| 10 | Бөтендөнья космонавтика көнен билгеләп үтү | | + | | |

***Май***

| № | Эш төре | I атна | II атна | III атна | IV атна |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Алдынгы эш тәҗрибәләрен өйрәнү, тарату | + | + | + | + |
| 2 | Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан хәтер көне | + | | | |
| 3 | Ата – аналар белән әңгәмә: “Бала мәктәптән ни көтә?” | | | + | + |
| 4 | Тематик тикшерү: Мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларның белем күнекмәләре. | | | + | + |
| 5 | Тәрбиячеләрнең портфолиоларын кабул итеп алу. | | | | + |
| 6 | Ата – аналардан анкета алу: “Быелгы уку елында бакча эшчәнлегенә фикерләрегез” | | + | + | |
| 7 | “Хуш – сөекле бакчабыз” – мәктәпкә әзерлек төркеме балаларын озату кичәсе | | | | + |
| 8 | “Кече Сабантуй” – бәйрәмен уздыру | | | | + |
| 9 | Оператив контроль: Балаларга хезмәт тәрбиясе бирү, чыныктыру чаралары, төркем бүлмәләрендә чисталык, төркемнәрдә документацияләрнең торышы | + | + | + | + |
| 10 | Балалар көче белән әзерләнгән “Без – яшь спортчылар” дип исемләнгән зур сәнгать бәйрәме | | | | + |

**Административ – хужалык эше.**

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Биналарга агымдагы кече ремонт үткәрү: агарту, буяу, чистарту, уен мәйданчыгындагы корылмаларны һәм спорт җихазларын яңарту. | Август - Май | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 2. | Территориядә эш: уен мәйданчыкларын чистарту | Сентябрь- Ноябрь, Май | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары,тәрбиячеләр |
| 3. | Төркемнәрне табигый һәм төзү материаллары, уенчыклар белән тәэмин итү | Даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 4. | Төркемнәрдәге уен почмакларына уенчык шкафлары алып куюга ирешү. | Ел дәвамында | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 5. | Бинаны кышка әзерләү:тәрәзәләрне | Сентябрь, Октябрь | Кече тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | замаска белән сылау, буяу, чистарту. | | |
| 6. | Уен мәйданчыгын яңа корылмалар белән баету, комнар кайтару, мәйданчыкны матурлау(әти-әниләр көче белән) | Май | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 7. | Чәчәк түтәлләре ясау өчен балчык кайтарту, әйләндереп алу. | Май. | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 9. | Спорт инвентарьләре алу өчен спонсорларны тарту (Туплар, кыршау,скакалкалар һ.б.) | Апрель | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 10. | Ел дәвамында бакча территориясен чистарту максатыннан өмәләр үткәрү | Ел дәвамында | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |

**Кугэрчен урта мәктәбе белән хезмәттәшлек итү**

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкә экскурсияләр һәм максатчан прогулкалар: | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 2 | Яңа уку елы башланганда «Белем» бәйрәмендә катнашу. | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 3. | Укытучылар коллективын һөнәри бәйрәмнәре белән котлау. | Октябрь | Тәрбиячеләр |
| 4 | Мәктәп белән таныштыру; класс, китапханә, спортзал,компьютер бүлмәсе. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 5 | I сыйныф укучыларының укулары бнлән кызыксынып тору, дәресләрендә булу. | Ел дәвамында | Педагогик коллектив |
| 6 | 1 нче сыйныф укучыларының «Әлифба» бәйрәмендә катнашып, котлау | Февраль | Тәрбиячеләр |
| 7 | Башлангыч сыйныф укытучыларын ата-аналар жыелышына, белем бирү эшчәнлекләренә чакыру, рәсемнәр күргәзмәсе. | Даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары, тәрбияче. |
| 8 | Мәктәпнең хоккей мәйданчыгы белән таныштыру, хоккей ярышларын карарга алып чыгу. | Кыш айларында | Тәрбиячеләр |
| 9 | Балаларны мәктәпкә әзерләү һәм озату кичәсе уздыру « Сау бул бакча.» | Май | Тәрбиячеләр |

**Чыныктыру-сәламәтләндерү буенча эш планы.**

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Балаларнын сәламәтлекләренең торышын һәм чисталыгын даими тикшереп тору | Даими | Тәрбияче, кече тәрбияче |
| 2. | Балаларнын физик яктан усешлэрен тикшеру ( авырлыкларын хэм буй озынлыкларын улчэу ) | Сентябрь, Январь | тәрбияче |
| 3. | Чыныктыру ысулларын куллана башлау<br>1.Авыз һәм тамак чайкау<br>2.Йокы алдыннан аякларны юу<br>3. Һава ванналары үткәрү | сентябрь<br>көн саен | тәрбияче |
| 4. | Ике атна дәвамында баларга поливитамин | октябрь | Кече тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бирү | | |
| 5. | Чыныктыру ысуллары алымнарын өйрәнүне дәвам итү<br>1.Авыз һәм тамак чайкау<br>2.Һава ванналары үткәрү<br>3.Төймәле келәмнән йөрү | октябрь | Тәрбияче, кече тәрбияче |
| 6. | Балаларга профилактик карау үткәрү (балаларнын чәчләрен, кулларын, тырнакларын ) | ай саен | Тәрбияче, кече тәрбияче |
| 7 | Профилактик прививкаларны вакытында ясау | даими | Авыл фельдшеры |
| 8 | Төркемдә «сетка стула» алып баруны контрольдә тоту | ел дәвамында | тәрбияче, кече тәрбияче |
| 9 | Балалар бакчасынын санитария -гигиена кагыйдәләренең үтәлешен контрольдә тоту. | ел дәвамында | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 10 | Вакытында дез. раствор ясау. | даими | Кече тәрбияче |
| 11 | Балалар бакчасында көндәлек режимның үтәлешен котрольдә тоту | даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |
| 12 | Йогышлы авырулар белән аралашкан балаларның сәламәтлеген күздә тоту | Даими | тәрбияче |
| 13 | Гәүдә тотышында, умырткалык баганасында төрле тайпылышлар булдырмас өчен дәвалау гимнастикасы өйрәтә башлау | ноябрь | тәрбияче |
| 14 | График буенча балаларның тизәкләрен суалчан авыруына анализга жыю һәм тапшыру. | ноябрь | Авыл фелдшеры, тәрбияче |
| 15 | төркем балаларын иртәнге фильтр аша бакчага кертү | даими | тәрбияче |
| 16 | Бүлмәләрдә һава режимын, бүлмә жиллэтүнең үтәлешен тикшереп тору | даими | тәрбияче |
| 17 | Гимнастика һәм физкультура белем бирү өлкәсе эшчәнлеге үтәлешен контрольдә тоту. | даими | тәрбияче |
| 18 | Ашханәдә савыт – сабаларның маркировкасын, чисталыгын тикшереп тору | даими | Мәктәпкәчә белем бирү директор урынбасары |

## Балаларының 2019 -2020 уку елына көндәлек эшчәнлекләрен оештыру һәм тәрбия бирү режимы

(елның салкын вакытына)

| Көн бүленеше | Кечкенәләр төркеме | Уртанчылар төркеме | Зурлар төркеме | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
|---|---|---|---|---|
| *Балаларны кабул итү, фильтр үткәрү, уеннар, индивидуаль эш, иртәнге гимнастика* | **7.30-8.30** | **7.30-8.30** | **7.30-8.30** | **7.30-8.30** |
| *Иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш* | **8.30-8.55** | **8.30-8.55** | **8.30-8.55** | **8.30-8.55** |
| *Белем бирү эшчәнлегенә әзерлек* | **8.55-9.00** | **8.55-9.00** | **8.55-9.00** | **8.55-9.00** |
| *Белем бирү эшчәнлеге: 1<br>2<br>3* | ***9.00-9.15<br>9.40-9.55*** | **9.00-9.20<br>9.40-10.00** | **9.00-9.25<br>9.40-10.00** | **9.00-9.30<br>9.40-10.10<br>10.20-10.50** |
| *Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге* | ***9.55-10.10*** | **10.00-10.10** | **10.00-10.10** | |
| *Икенче көндезге аш* | **10.10-10.20** | **10.10-10.20** | **10.10-10.20** | **10.10-10.20** |
| *Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге* | **10.20-10.40** | **10.20.10.40** | **10.20.10.45** | |
| *һавага чыгарга әзерлек* | **10.40-10.45** | **10.40-10.50** | **10.45-10.55** | **10.50-11.00** |
| *Һавада булу (күзәтү,уеннар, хезмәт, мөстәкыйль эшчәнлек)* | **10.45-12.10** | **10.50-12.15** | **10.55-12.20** | **11.00-12.25** |
| *Урамнан керү, көндезге ашка әзерлек* | **12.10-12.30** | **12.15-12.30** | **12.20-12.30** | **12.25-12.30** |
| *Көндезге аш* | **12.30-13.00** | **12.30-13.00** | **12.30-13.00** | **12.30-13.00** |
| *Йокларга әзерләнү , көндезге йокы* | **13.00-15.00** | **13.00-15.00** | **13.00-15.00** | **13.00-15.00** |
| *Йокыдан тору, һава, су процедуралары, төштән соңгы ашка әзерлек* | **15.00-15.15** | **15.00-15.15** | **15.00-15.15** | **15.00-15.15** |
| *Төштән соңгы аш* | **15.15-15.30** | **15.15-15.30** | **15.15-15.30** | **15.15-15.30** |
| *Белем бирү эшчәнлеге* | | | **15.30-15.55 (дүшәмбе, сишәмбе, пәнҗишәмбе)** | |
| *Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек, хезмәт* | **15.30-15.55** | **15.30-15.55** | **15.30-15.55 (чәршәмбе, җомга)** | **15.30-15.55** |
| *һавага чыгарга әзерлек,һавада булу, уеннар* | **15.55-16.30** | **15.55-16.30** | **15.55-16.30** | **15.55-16.30** |
| *өйләренә озату* | **16.30** | **16.30** | **16.30** | **16.30** |